ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 01 » июль 2016 ел** **№ 724**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» Арча район башкарма комитетының 01.04.2013ел, №429 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» Арча район башкарма комитетының 2013 елның 01 апрелендәге 429 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә һәм аны кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.Е. Спичкинга йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
01. 07. 2016 ел, № 724
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге**

***Җирле үзидарә органнарына тапшырылган вәкаләтләр буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү***

1. Язылышуны теркәү.
2. Баланың тууын теркәү.
3. Никахны өзүне теркәү.
4. Ата булуны билгеләүне теркәү.
5. Исемне үзгәртүне теркәү.
6. Уллыкка (кызлыкка) алуны теркәү.
7. Үлемне теркәү.
8. Гражданхәле актларын язуга үзгәрешләр кертү.
9. Гражданхәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында кабат таныклыклар яисә граждан хәле актын дәүләт теркәвенә алмауны раслый торган башка документлар бирү.
10. Дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклана торган архив фондлары буенча архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документларының күчермәләрен бирү.
11. Дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклана торган архив документларын муниципаль архивның уку залында эшләү өчен кулланучыга бирү.
12. Архив эшендә методик һәм практик ярдәмне дәүләт милкендәге юридик затларга бирү һәм эш башкаруда документларны оештыру - хезмәт күрсәтү (функционал) булып тормый.
13. Дәүләт милкенә кертелгән архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация.
14. Оешмалардан саклау өчен документлар кабул итү.
15. Тәрбияләнүчеләрне психоневрология тибындагы интернат-йортларга стационар хезмәт күрсәтүгә җибәрү турында карарлар бирү.
16. Суд тәртибендә хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затка карата опека яисә попечитель билгеләү һәм опекун яисә попечитель билгеләү.
17. Гомерлеккә якын кеше мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзүгә рөхсәт бирү.
18. Балигъ булган хокуктан файдалануга сәләтсез зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга опекунга рөхсәт бирү.

19. Опекунга үз карамагындагы кешенең фатирын наемга тапшыруга рөхсәт бирү.

20. Тәрбияләнүчеләрнең мөлкәте белән алыш-биреш кылуга рөхсәт бирү.

21. Яшәү урыны алмашынуга бәйле рәвештә, опекунга яшәү урыны буенча теркәлү исәбен алып баруга рөхсәт бирү.

22. Опекунга яисә попечительгә тәрбиядәге баланың нәсел хокукларына керүгә рөхсәт бирү.

23. Опекунга яисә попечительгә тәрбиягә алучының саклык счетын файдалануга рөхсәт бирү.

24. Ятим балалар өчен оешмаларда булган балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган граждапнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү.

25. Балигъ булмаган (алар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү.

26. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алучыларга кандидат буларак исәпкә кую.

27. Балигъ булмаганнарның күчмә милкен читләштерү буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү.

28. Ундүрт яшькә житмәгән баланың исемен һәм (яисә) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү.

29. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, гражданнарга (түләүле яисә түләүсез шартларда) опека (попечительлек) билгеләү яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү.

30. Балигъ булмаган баланы эмансипацияләү мөмкинлеге турында карар кабул итү (балигъ булмаганны тулысынча эшкә сәләтле дип игълан итү).

31. Балигъ булмаган яшьтәге күчемсез милекне читләштерү буенча килешүне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү.

32. Торак сатып алуга кредит акчаларыннан файдаланып алдан рөхсәт бирү һәм аны, балигъ булмаганнар катнашында залогка (ипотекага) тапшыру.

33. Балигъ булмаганның акчалата кертеме алу өчен законлы вәкилгә рөхсәт бирү.

34. Суд тәртибендә социаль учреждениедә стационар хезмәт күрсәтүдә булган хокукка сәләтсез дип танылган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарның гаиләләренә вакытлыча тапшыру турында бәяләмә бирү.

35. Уналты яшькә житмәгән затка (затларга) никахлашуга рөхсәт бирү.

36. Баланы (балаларны) матди карап торуга опекунга яисә попечительгә, тәрбиягә бала алучы ата-аналарга акчалар билгеләү һәм түләү, шулай ук опекуннарга яисә попечительләргә, үз вазыйфаларын түләүле үтәүче тәрбиягә бала алучы ата-аналарга түләү.

37. Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү

программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына исәпкә кую һәм исәпкә алу.

*Муниципаль хезмәтләр күрсәтү*

1. «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча торак сатып алуга (төзелешкә) социаль түләү алуга хокук турында таныклык исәпкә кую һәм бирү.
2. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтажларны исәпкә кую.
3. Торак урыннарына мохтаж аерым категориядәге гражданнарны исәпкә кую.
4. Чернобыль АЭСында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга, «Маяк» житештерү берләшмәсендәге аварияләргә һәм аларга тиңләштерелгән затларга исәпкә кую һәм Дәүләт торак сертификатын бирү.
5. Торак шартларын яхшыртуга мохтажлар буларак исәпкә кую һәм күченеп килергә мәҗбүр булганнарга торак сатып алуга субсидия бүлеп бирүгә дәүләт торак сертификаты бирү.
6. Торак бинаны үзгәртеп коруга һәм (яки) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү.
7. Торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү.
8. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектәге торак урын бирү.
9. Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле итеп тану.
10. Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәр бирү.
11. Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү.
12. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү.
13. Территорияләрнең кадастр планында җир кишәрлеге яисә җир кишәрлекләре схемасын раслау.
14. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү
15. Җир эшләрен җитештерүгә ордер бирү.
16. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү.
17. Төзелеп бетмәгән объектны файдалануга рөхсәт бирү.
18. Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү.
19. Күчемсез милек объектын бирү (үзгәртү, тогәлләштерү, гамәлдән чыгару).
20. Күпфатирлы торак йортның беренче катында урнашкан фатирда балкон (лоджия) төзелешен килештерү.
21. Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү.

22. Милекчеләргә һәм кулланучыларга жирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектына сак йөкләмәләрен рәсмиләштерү.

23. Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр житештерүчеләргә субсидияләр бирү.

24. Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү.

25. Агач һәм куакларны кисүгә, кронировкалауга яисә утыртуга рөхсәт бирү.

26. Авыр йөк һәм эре габаритлы йөкләрне муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә узучы маршрутлар буенча автомобильдә йөртүгә рөхсәт бирү.

27. Жирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү.

28. Муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә итү хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында муниципаль мөлкәтне рәсмиләштерү (беркетү).

29. Җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү.

30. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү.

31. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү.

32. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сату.

33. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү.

34. Җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар милеккә яисә арендага бирү.

35. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион рәвешендә уздырыла торган торгларда арендага бирү.

36. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион рәвешендә уздырыла торган торгларда җир кишәрлеген сату юлы белән милеккә бирү.

37. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү.

38. Муниципаль милектәге җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү.

39. Крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына муниципаль милектәге җир кишәрлеген милек буларак (арендага) бирү.

40. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү.

41. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бакчачылыкны алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү.

42. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген дача хуҗалыгын алып бару өчен гражданнарга милек буларак (арендага) бирү.

43. Хосусый яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер

категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) икенчесенә күчерү турында карар кабул итү.

44. Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын туктату.

45. Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү.

46. Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү.

47. Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү.

48. Муниципаль преференцияләр бирү.

49. Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау.

50. васыять кәгазе һәм ышанычнамә таныклыгы.

51. Белешмә (өземтә) бирү.

52. Социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлекләренә кертү һәм авыл җирлегендә торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклык бирү.

53. Ана (гаилә) капиталын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслый торган документ бирү.

54. Милеккә җир кишәрлекләрен түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак затларны исәпкә кую.

55. Муниципаль милектәге һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүмат бирү.

56. Казнаның муниципаль мөлкәтен арендага бирү.

57. Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут билгеләү турында килешү төзү.

58. Әлек хосусыйлаштырылган торак биналарын муниципаль милеккә кабул итү.

59. Муниципаль милек реестрына керүче муниципаль мөлкәтне арендага бирү.

60. Җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалану төрен үзгәртү.

61. Җир кишәрлеген гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләре әгъзасы булган гражданга түләүсез бирү.

62. Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү.

63. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль мөлкәтне биләүгә һәм (яисә) аннан файдалануга тапшыру.

64. Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләре гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлеген бирү.

65. Торглар үткәрмичә муниципаль берәмлекнең муниципаль мөлкәтен түләүсез файдалануга тапшыру.

66. Мондый шартнамә төзү хокукына сатулар нәтиҗәләре буенча муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсе төзү.

67. Объектны урнаштыру урынын алдан килештерү турында карар

кабул итү.

68. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне бирү.

69. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга индивидуаль торак төзелеше өчен милеккә (арендага) бирү.

70. Муниципаль милекне арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү.